**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№12179**
**15.12.2023**

Башкарма комитетның «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5734 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Яр Чаллы шәһәре территориаль иҗтимагый үзидарәсенең тотрыклы эшләве һәм үсеше өчен шартлар тудыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5734 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2021 елның 19 мартындагы 1902 номерлы, 2022 елның 14 июлендәге 3558 номерлы, 2022 елның 3 октябрендәге 5191 номерлы, 2023 елның 20 апрелендәге 3185 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны шәһәр бюджеты акчалары хисабына «Төзекләндерү» 05.03 бүлеге (бүлекчәсе) буенча 3 190,0 мең сум, «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча 63 596,7 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2021 ел – 5 500 мең сум, 2022 ел – 26 060,8 мең сум, 2023 ел – 32 035,9 мең сум.»;

2) кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы

рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы Л.И. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 15 декабрендәге
12179 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2020 елның 30 октябрендәге
5734 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек. «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәренең
территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү»
муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаның исеме | «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Карары белән расланган шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2014 елның 17 апрелендәге 30/18 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре,<br>Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре,<br>Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| Программаның максаты | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең тотрыклы эшләве һәм үсеше өчен уңайлы шартлар формалаштыру |
| Программаның бурычлары | 1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүдә җирле үзидарә органнарының һәм территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының үзара эшчәнлеге системасын үстерү һәм камилләштерү.<br>2. Яр Чаллы шәһәрендә халыкны территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенә җәлеп итү. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2021-2023 еллар.<br>- 1 этап – 2021 ел;<br>- 2 этап – 2022 ел;<br>- 3 этап – 2023 ел. |

<table>
<tr><td rowspan="8">Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары (мең сум)</td></tr>
<tr><td>2021 ел</td><td>2022 ел</td><td>2023 ел</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>5 500,0</td><td>0,0</td><td>3 540,0</td><td>9 040,0</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>26 060,8</td><td>31 685,9</td><td>57 746,7</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы:</td><td>5 500,0</td><td>26 060,8</td><td>35 225,9</td><td>66 786,7</td></tr>
<tr><td colspan="5">Программаны тормышка ашыруга тотыла торган акчаларның күләме шәһәр бюджеты мөмкинлекләреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге инфляция процессларыннан һәм икътисадый хәлдән чыгып анықланырга һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2023 елга түбәндәгеләрне арттыру күздә тотыла:<br>1) территориаль иҗтимагый үзидарәләр тарафыннан үткәрелгән чаралар саны;<br>2) территориаль иҗтимагый үзидарәләр тарафыннан тормышка ашырылган социаль әһәмиятле проектлар саны;<br>3) территориаль иҗтимагый үзидарәләр чараларында катнашуга җәлеп ителгән Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләр саны.</td></tr>
<tr><td>Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td colspan="5">Программаның үтәлешенә гомуми контрольне Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Программаны тормышка ашыру өлкәсе характеристикалары, күрсәтелгән өлкәдәге төп проблемаларга тасвирлама һәм аны үстерү прогнозы

Территориаль иҗтимагый үзидарә (алга таба – ТИҮ) булып, мөстәкыйль рәвештә һәм үз җаваплылыгында җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча үз инициативаларын гамәлгә ашыру өчен, шәһәр территориясе өлешендә яшәү урыны буенча гражданнарның оешмалары тора.

ТИҮ җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча халыкның үз инициативаларын тормышка ашыруга мөмкинлек бирә һәм җирле берләшмәләрнең проблемаларын хәл итүдә мөһим роль уйный.

Беренчедән, ТИҮ – җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен Яр Чаллы шәһәре халкының интеллектуаль, фәнни, мәдәни потенциалын киң файдалану мәйданчыгы ул.

Икенчедән, ТИҮдә катнашучылар халык проблемалары һәм сораулары турындагы мәгълүмат оператив рәвештә җирле үзидарә органнарына барып ирешә торган оештырылган мәгълүмат каналы булып тора. Шул ук вакытта, ТИҮ органнары җирле үзидарә органнарыннан мөһим мәгълүматны халыкка җиткерү чарасы да булырга мөмкин.

Өченчедән, ТИҮ – ачыкланган проблемаларны чишү, гражданнарның үз сорауларын хәл итү өчен төп чара ул.

Хәзерге вакытта Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 78 территориаль иҗтимагый үзидарә рәсми теркәлгән һәм эшли.

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр системасын формалаштыру төгәлләнә һәм шуның өчен ул җирле үзидарә органнары ягыннан җайга салуга, камилләштерүгә һәм ярдәмгә мохтаҗ.

Гамәлдәге ТИҮнең эш процессында күп кенә төп проблемалар ачыкланды:

1) үзидарә өлкәсендә хокукларны гамәлгә ашыру буенча халыкның активлыгы җитәрлек булмау;

2) ТИҮнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлегенең төгәл механизмы булмау;

3) ТИҮнең материаль-техник ятан тәэмин ителеше җитәрлек булмау;

4) ТИҮ оештыру һәм аның эшчәнлек юнәлешләре мәсьәләләре буенча халыкның хәбәрдарлык дәрәҗәсе түбән булу.

Шәһәр бюджетыннан финанс ярдәме күрсәткәндә, югарыда күрсәтелгән проблемаларны хәл итүгә комплекслы һәм системалы якын килү ТИҮ үсешенә нәтиҗәлерәк булышлык итәргә мөмкинлек бирә.

## 3 бүлек. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, аны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

Максат – ТИҮнең тотрыклы эшләве һәм үсеше өчен уңайлы шартлар тудыру.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1) җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүдә җирле үзидарә органнары һәм ТИҮ органнарының үзара эшчәнлеге системасын үстерү һәм камилләштерү;

2) Яр Чаллы шәһәрендә халыкны ТИҮ эшчәнлегенә җәлеп итү.

Программа 2021-2023 елларда тормышка ашырыла.

Программаны тормышка ашыру этаплары:

- 1 этап – 2021 ел;
- 2 этап – 2022 ел;
- 3 этап – 2023 ел.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирүче индикаторлар

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрдән файдаланырга тәкъдим ителә:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү методикасы | Чыганагы |
|---|---|---|---|
| 1 | ТИҮ катнашында үткәрелгән чаралар саны | N – үткәрелгән чараларның гомуми саны | |
| 2 | ТИҮ чараларында катнашуга җәлеп ителгән Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләр саны | N – ТИҮ чараларында катнашуга җәлеп ителгән шәһәрдә яшәүчеләр; | |

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2021-2023 елларга программаны финанслау күләме 66 786,7 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары:

Чор өчен барлыгы 66 786,7 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2021 ел – 5 500,0 мең сум, 2022 ел – 26 060,8 мең сум, 2023 ел – 35 225,9 мең сум.

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программа чараларын тормышка ашыру барышына контрольне Башкарма комитетның районнар хакимиятләре гамәлгә ашыра.

Программаның нәтиҗәлелеген анализлау Башкарма комитетның 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

7 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| № т/б | Чараларның исеме | Башкаручылар | Чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Программа чараларын муниципаль бюджеттан финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2020 (база) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| | Максатның исеме: Территориаль иҗтимагый үзидарәнең тотрыклы эшләве һәм үсеше өчен уңайлы шартлар формалаштыру | | | | | | | | | | |
| | Бурычның исеме: 1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүдә җирле үзидарә органнары һәм территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының үзара эшчәнлеге системасын үстерү һәм камилләштерү | | | | | | | | | | |
| 1. | «Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» конкурслары оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (оештыруда ярдәм күрсәтү өлешендә) | 2021 -2023 еллар | Шәһәрнең ТИҮ органнары составына сайланган ТИҮдә катнашучылар, ТИҮнең структур берәмлекләре һәм комиссияләре саны/ТИҮ тарафыннан үткәрелә торган чараларда катнашуга җәлеп ителгән халык саны (кеше) | 1000/ 40000 | 1200/ 42000 | 1500/ 45000 | 1500/ 46000 | 350,0 | 0,0 | 350,0 |
| 2. | Яр Чаллы шәһәре территориаль иҗтимагый үзидарәсенең төзекләндерү һәм (яки) яшелләндерү буенча иң яхшы проекты | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык | 2021-2023 еллар | ТИҮнең төзекләндерү буенча конкурска чыгарылган проектлары саны/ТИҮ тарафыннан тормышка | 77/42 | 77/45 | 77/50 | 78/55 | 5100,0 | 0,0 | 3 190,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | яшәешен тәэмин итү идарәсе (оештыруда ярдәм күрсәтү өлешендә) | | ашырылган һәм шәһәр бюджетыннан финансланган социаль әһәмияткә ия проектлар саны | | | | | | | |
| 3. | Яр Чаллы шәһәре территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләре тарафыннан компенсация түләүләре алу | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (оештыруда ярдәм күрсәтү өлешендә) | 2021-2023 еллар | Яр Чаллы шәһәре территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыручы ТИҮ саны/ Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләүләре алучы ТИҮ саны | - | - | 77/77 | 78/78 | 0 | 16 518,8 | 17 685,9 |
| 4. | «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында катнашу | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (оештыруда ярдәм күрсәтү өлешендә) | 2021-2023 еллар | Республика конкурсына ТИҮ тарафыннан куелган проектлар саны/Республика бюджетыннан финанслау алган ТИҮ тарафыннан тормышка ашырылган социаль әһәмияткә ия проектлар саны | - | - | 22 | - | 0 | 9 542,0 | 14 000,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурычның исеме: 2. Яр Чаллы шәһәрендә халыкны ТИҮ эшчәнлегенә җәлеп итү | | | | | | | | | | | |
| 5. | Спортның ишегалды төрләре фестивален оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (оештыруда ярдәм күрсәтү өлешендә) | 2021-2023 еллар | Чараларда катнашуга җәлеп ителгән Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләр саны (кеше) | 2000 | 2200 | 2300 | 2500 | 50,0 | 0,0 | 0,0 |
| | Барысы | | | | | | | | - | - | - |
| | Программа буенча барлыгы: | | | | | | | | 5 500,0 | 26 060,8 | 35 225,9 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева